ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 16.12.2016 г. Казань № 5-60/тэ

«Түбән Кама ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган җылы йортүчегә тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 20 ноябрендәге № 5-28/тэ санлы Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән «Түбән Кама ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган җылы йортүчегә озак сроклы тарифларны 2017 елга үзгәртү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Түбән Кама ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган җылы йортүчегә тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 20 ноябрендәге № 5-28/тэ санлы Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты карарына, әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 16.12.2016 № 5-60/тэ
карарына кушымта
«Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 20.11.2015 № 5-28/тэ
карарына 1 кушымта

## 2016-2018 елларга календарьга бүлеп «Түбән Кама ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган җылы йөртүчегә тарифлар

| № п/п | Көйләнүче оешманың атамасы | Тариф төре | Ел | Җылы йөртүче төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | Җылы йөртүче җитештерелә торган җылылык энергиясе чыганагына (чганакларныа) ия булучы җылылк белән тәэмин итүче оешма тарафыннан бирелә торган җылы йөртүчегә тариф | | | | |
| 1.1 | «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ | Бер ставкалы, сум./Гкал | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 24,85 | 43,00 |
| | | | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 26,75 | 51,94 |
| | | | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 26,73 | 46,40 |
| | | | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 27,75 | 48,48 |
| 2 | Кулланылышка куела торган җылы йөрткечкэ тариф | | | | |
| 2.1 | «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ | Бер ставкалы, сум./Гкал | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 24,85 | 43,00 |
| | | | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 26,75 | 51,94 |
| | | | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 26,73 | 46,40 |
| | | | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 27,75 | 48,48» |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге